

Без яшьрәк чакта, ноябрь азакларында декабрь башларында, авылда һәр шимбә-якшәмбедә сугым суела иде. Әле ел әйләнәсендә дә бу эшне башкарып була, чонки зур суыткычлар бар.

Кар тошкәч, ноябрьдә, каз-vрдәк омәләре vтә, инде ныклап катыргач, олы мал суела. Ул елларда суыткычлар рәтләп юк иде әле, шуна кvрә коннәрнен ныклап суытуы шарт иде. Таштан ясалган базларга башта кар тутырып тундырырга кирәк, аннары җәй коне дә шул «холодильник»та ашамлыклар саклана иде.       Эмәләргә килгәндә, кvпме каз-vрдәк суюга карап, һәр хатын-кызга ике-оч баш туры килерлек итеп, vзендә дә суяр кош-корты булган кvршесе, туган-тумачасы чакырыла. Эш барышында, жырнын жыртыгы юк дигәндәй, «Туган авылым», «Кvбәләгем»нән башлап, «Тала-тала» белән «Сарман», «Алмагачлары»н сузып, рәхәтләнеп кvнел ача иделәр. Бер-беренә торттереп торле шаян такмаклар да жырлый иделәр. Шулай бер-берләренә кул алмаш йоргәннәр һәм бvген дә, ягы-ягы белән, эмәгә йорvләрен дәвам итәләр. Бу кош-кортларны йолку, чистарту бик нык осталык сорый торган эш. Йонын кvбрәк эләктереп тартсан, тиресе дә йолкынып чыга, кош тvшенен яме китә. Элек vтvкләп йолка иделәр, бvген кипятокка салып та йолку бар. Ә каз-vрдәк кvбрәк кvчтәнәчкә тотыла, чит тобәкләрдә туган-тумачан булса, посылка белән шәһәр тирәсенә китә иде. Бу бvген дә шулаен шулай. Туйларга, кунакка барган чакларда шулай ук каз-vрдәкнен кирәге чыга.

Олы малны ир-ат эмәләр ясап суйгач, эчәкләрен хатын-кыз эшкәртәләр иде. Ул эчәк-карталар vзенә берторле тәмле була торган иде. Аларны кайнар суда пешекләп чистартыла; бернинди ис-фәлән дигән нәрсә калмый. Шуны чыжлап торган майда кыздырсан – теленне йотарсын...Бvген дә андыйлар югалмаган дип уйлыйм. Темник районы Тархан авылы халкы эшкә матурлар. Алардан сугым итен сатып алырга Ельник, Краснослабодск район татарлары хәзер дә киләләр.

Кышнын авызы зур бит, барысы да ашала. Сугым чалган конне мул итеп ливерларны һәм итне кушып селянка пешергәч, ашап туймаслык ризык була. Ә холодецны, әйтәсе дә юк! Сугым итенен йомшагы кvп була һәм мулдан ит ашлары (мәсәлән, пәрәмәчнен майда пешкәне дә, мичтә пешкәне дә) тәмле. Ә казылык турында аерым сvз алып сойлисе килә.Бер борынгы рецепт белән уртаклашасы килә. Аны әзерләv очен ат итен вак итеп турарга һәм тоз-борычны яхшылап ышкып сендерергә кирәк. Әзер эчлекне кәстрvлгә салырга һәм остенә тастымал каплап, 15 сәгатьтән алып тәvлек ярымга чаклы салкында тоталар.

Ат яки сыер эчәкләрен яхшылап эшкәрткәннән сон, бер башын жеп белән бәйләп, әзер эчлекне тутыралар. Ит белән майны чиратлаштырырга кирәк, итнен майлылыгы чама

белән утыз процентны тәшкил итәргә тиеш. Май кvп булганда, агып чыксын очен, эчәкләрне берничә жирдән энә белән тишәләр. Эчәкләрне тутырып бетергәч, икенче башын да бәйләргә һәм берничә конгә жилле-кояшлы урынга элеп куярга кирәк. Шуннан сон 2-2,5 айга карангы урынга кvчереп куялар. Өзер казылыкнын саклану вакыты – дvрт-биш ай, аны чи килеш тә, пешереп тә ашап була.
Пешергәндә казылыкны кәстрvлгә жылы су белән салып, сvрән утка куярга кирәк. Су кайнап чыккач, тышын берничә жирдән энә белән тишәргә һәм тагын сәгать ярым кайнатырга туры киләчәк. Табынга чыгарганда, мае һәм формасы саклансын очен, калынрак итеп кисәләр. Борынгыдан калган гадәт буенча, кvбрәк шулай тәмле пешереп Атюрьево, Ельник, Ковылкино, Краснослабодск, Торбеево, Темниково районнарында яшәгән татар милләтле халык ашый. Гадәт бvген дә саклана.

**Н.Хәлил**